*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Наласа гомуми үсеш бирү төрендәге “Балачак” балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*



# Чишмә башы

*№ 1*

*Сентябрь , 2025 ел*



***Ата-аналар һәм балалар өчен кызыклы мәгълүматлар***

## "Көз йөри"

Каурыйларда көз көйләрен уйнап,
Агачларны сары төскә буяп,
Куакларга җиләк-җимеш элеп,
Агач төпләренә гөмбә тезеп,
Урам буйлап алтын көз йөри.

Көшел-көшел бодай, арыш җыеп,
Саламнардан зур эскертләр куеп,
Кара җирне ужым белән каплап,
Тракторлар белән гөрләп, шаулап,
Кырлар буйлап уңган көз йөри.

Безне җылы бакчаларга дәшеп,
Аяк асларына яфрак чәчеп,
Тәрәзләрне яңгыр белән юып,
Күп кошларны җылы якка куып,
Урам буйлап наян көз йөри.

Гәрәй Рәхим

## КӨЗ ТУРЫНДА ХАЛЫК СЫНАМЫШЛАРЫ

- Кояш батканда аяз булып, төньяктан салкынча җил булса, кырау төшәр.
- Имәндә чикләвек күп булса, кыш салкын килә.
- Суганның кабыгы ике кат булган елны кыш җылы булыр, ә кабыгы күпкатлы булган елны кыш салкын булыр.
- Урманда чикләвек күп булса, кыш кырыс булачак.
- Көз көне каен агачлары астан саргаеп, яфракларын астан коя башласалар – кыш җылы килә, ә өстән саргаеп, өстән яфрак коя башласалар – кыш салкын килә.
- Кыр казлары иртә китсә, кыш иртә килә.
- Көз көне кошлар түбән очса, кыш – салкын, югары очса, кыш җылы килә.
- Көз көне куяннар бер эздән йөрсә, кыш көне кар күп явар.














Балалар бакчасында «Белем көне» -яңа уку елы башлануны һәм балаларның белем һәм иҗат дөньясы белән танышу мөмкинлеген билгеләп үтүче мөһим вакыйга. Балалар бакчасында тәрбияләнүчеләрне Белем көне белән котларга әкият персонажлары: Мальвина һәм Буратино, урманнан тычкан «Чи-Чи» килде. Балалар килгән кунаклар белән бәйгеләрдә катнаштылар, табышмаклар чиштеләр, җырлар җырладылар,биеделәр, шаярдылар һәм көлделәр. Балаларга, Белем көне истәлеге итеп, әкият китаплары бүләк иттек. Безнең балалар бакчасында яңа уку елы менә шулай күңелле, кызыклы һәм бәйрәмчә башланды. Балалар бәйрәмнән зур шатлык, уңай һәм якты тәэсирләр алдылар. Безнең балалар бакчасында яңа уку елының беренче көне һәрвакыттагыча күңелле һәм эмоциональ узды.













**«Әти-әниләр җыелышы»**

Бакчабызда әти-әниләр җыелышы булып узды. Яңа уку елына максат һәм бурычлар, адаптация чоры, көндәлек режим, шөгыльләр тәртипләре, эчке тәртипләр, балаларның куркынычсызлыгы буенча чыгышлар тыңланды, инструктажлар үткәрелде. Экологик тәрбия алымнары практикада күрсәтелде.
















**«Терроризм - глобальная проблема современного мира».**




Сегодня в нашем детском саду прошла тематическая беседа «Терроризм - глобальная проблема современного мира». В доступной и понятной для детей форме мы обсудили, что такое терроризм, почему он опасен, и как важно соблюдать правила безопасности. Ребята активно задавали вопросы, делились своими мыслями и выражали свое мнение. Мы подчеркнули, что мир и безопасность – это самая главная ценность, и что каждый из нас может внести свой вклад в их сохранение. Мы верим, что такие беседы помогают формировать у детей ответственное отношение к своей безопасности и развивать чувство солидарности в борьбе за мир.






**«Тормыш тамчысы» акциясе**

Ел саен 3 сентябрьдә Россиядә истәлекле дата - терроризмга каршы көрәштә бердәмлек көне билгеләп үтелә һәм «Тормыш тамчысы» Бөтенроссия акциясе уздырыла.Акция 2004 елның беренче сентябрь көннәрендә Бесланда булган фаҗигале вакыйгаларга багышлана. Ул вакытта, 1 нче мәктәптә террорчылык акты вакытында берничә йөз кеше һәлак булган, алар арасында күпчелеге балалар. Өч көн тоткынлык дәвамында алар бер тамчы су да эчә алмадылар. «Тормыш тамчысы» акциясе-ул хәтер билгесе, безнең арада булмаган кешеләрне чәчәкләргә су сибү аша символик рәвештә тукландырырга өндәү. Без дә бергәләп корбаннарны искә алу һәм террорчылыкка каршы көрәштә теләктәшлегебезне белдерү өчен "Тормыш тамчысы" акциясенә кушылабыз.






**«Тынычлык территориясе» республика акциясе.**

Акциянең максаты - әйләнә- тирәдәгеләргә карата толерант мөнәсәбәтне үстерү

## «Музейга экскурсия»

Балалар белән мәктәпкә экскурсиягә бардык.Туган як музее җитәкчесе Хасанова Айгөл Миннур кызы балаларга аңлаешлы итеп халкыбызның көнкүреше, тарихы белән таныштырды. Музей тарихи материалга бик бай, балалар бик кызыксынып тыңладылар. Спорт мәйданчыгында да булдык. Мәктәп бакчасында үсүче чәчәкләр,агачларны да күзәттек. Экскурсия балаларга бик ошады.











## «17 сентябрь -юл хәрәкәте иминлеге көне »

Шул уңайдан, балалар бакчасында тематик чаралар оештырылды. Балалар юл йөрү кагыйдәләрен үзләштерде һәм булган белемнәрен ныгыттылар. Аларны киләчәктә куркынычсыз һәм хәвефсез юллар көтсен. Юлларда сак булыйк, юл кагыйдәләрен төгәл үтик.





## «Солдатка рәсем» акциясенә кушылабыз

Балалар әти-әниләре белән берлектә күңел кылларына үтеп керә торган рәсемнәр ясадылар. Әлеге рәсемнәр хәзерге вакытта өйләреннән еракта булган егетләрнең күңелләренә җылылык бирсен .





## «Безнең уңышлар»

### IV Районара «Гариф Ахунов» укулары

Тәрбиячебез Шаһева Алсу Корбангали кызы Г.Ахунов исемендәге Казанбаш төп мәктәбендә якташ язучыбыз Гариф Ахуновнын тууына 100 елга багышланган IV районара укуларда « Балалар бакчасында туган якка мәхәббәт тәрбияләүдә Г.Ахунов иҗаты» дигән темага осталык шөгыле күрсәтеп, җиңүче дипломы белән бүләкләнде. Котлыйбыз!








### «Татар экиятләре һәм мультфильмнары геройлары»

Район күләмендә уздырылган «Татар әкиятләре һәм мультфильмнары геройлары» дип аталган рәсем конкурсында катнашып, бакчабызда тәрбияләнүче Мөхәммәтҗанова Зәлия I урын, Исхакова Зәлия II урын, Төхфәтуллин Йосыф II урын, Төхбәтуллина Ясминә III урын, Шаһиев Самат катнашучы дипломнарына лаек булдылар. Чын күңелдән котлыйбыз уңышларының дәвамлы булуын телибез.















## «Тәрбиячеләр һәм бакча хезмәткәрләре көне»

27 сентябрь – илебездә тәрбияче һәм балалар бакчасы хезмәткәрләре көне.

Шушы өлкәдә эшләүчеләрне чын күңелебездән һөнәри бәйрәмегез - Тәрбиячеләр көне белән котлыйбыз! Тәрбияче хезмәте - авыр һәм фидакарь хезмәт.Һөнәри бурычыгызга тугъры калуыгыз һәм балаларга күрсәткән игътибарыгыз өчен рәхмәт сезгә. Эшләү дәрте сүрелмәвен, балалар белән үзара аңлашу һәм һөнәрегезгә тугрылык телибез. Һәрвакытта һәм һәркайда уңышлар юлдаш булсын!

Синдәдер ул йөрәкләрнең иң олысы,
Синдәдер ул кулларның иң җылысы,
Һәр көн сиңа ничә сабый карап тора,
Алар сине әниседәй якын күрә.
Еласалар - син аларны юатасың,
Боексалар - син аларны уйнатасың,
Сөйләшәсең күңелләрен аңлап кына,
Орышасың кайчагында җайлап кына.
Үз улыңдай, үз кызыңдай якын күреп,
Үстерәсең ничә буын балаларны
Киткән чакта бакча белән саубуллашып,
Елый - елый озатасың син аларны.
Кирәк чакта сабыр да син, батыр да син.
Бик җаваплы, авыр синең хезмәтең дә,



## Туган көн белән котлыйбыз!

Сентябрь аенда кечкенәләр төркеменә йөрүче балаларыбыз: Билалова Зәйнәп, Гайнетдинов Кәрим һәм зурлар төркеменә йөрүче кызыбыз Мөхетдинова Әнисә туган көннәрен билгеләп үттеләр. Балаларга сәламәт, озын гомерле, бәхетле, акыллы, тәүфыйклы булып, эти-әни тигезлегендә үсүләрен телибез.






***Газетаны оештыручы һәм баш мөхәррир:*** *Хәсәенова Р.Н. , Галиуллина А.Ф.*
***Редколлегия әгъзалары***: *Гафурова Р.А., Шагиева А.К., Гафурова Э.Р.*
*Адрес: 422018 ТР,Арча районы, Наласа авылы, Үзәк урам, 76 йорт*